Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бута авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

15 ноябрь 2022 ел № 17

Әлмәт муниципаль районы Бута
авылы башкарма комитетының кайбер
карарларына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә таләпләр турында»2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карары нигезендә

Бута авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Бута авылы башкарма комитетыныңкайбер карарларына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2022 елның 25 июлендәге 10 номерлы карарына 1 нче кушымтаның 3.3.2.1 пунктындагы «16 яшькә җиткән балигъ булмаганнарга никахлашуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат - логик тикшерү органы (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер соратып алу формасындагы кырларны тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Соратып алу электрон формадагы дөрес тутырылмаган кырлары бердәм порталы белән ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры электрон рәвештә хәбәр итү аша җиткерелә.»;

1.2. 2022 елның 6 апрелендәге 5 номерлы карарына 1 нче кушымтаның 3.3.2.1 пунктындагы «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» (Әлмәт муниципаль районы Ямаш авылы башкарма комитетының 2022 елның 25 июлендәге 9 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып)унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган запросны формат - логик тикшерү орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүченең һәрбер соратып алу формасындагы кырларны тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан башкарыла. Соратып алу электрон формадагы дөрес тутырылмаган кырлары бердәм порталы белән ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры электрон рәвештә хәбәр итү аша җиткерелә.»;

2.Әлеге карарны Бута авылы, Сельская урамы, 28А йорты, территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Бута авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Д.Е. Абрамов